**Татарстан Республикасы Ютазы район Советы**

**КАРАР № 8**

Чираттан тыш III чакырылыш утырышы шт Урыссу бистәсе

2018 елның 23 март

*Ютазы муниципаль районының 2018нче елга муниципаль милекне приватизацияләүнең прогноз планын(программасын) раслау турында*

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 14 маддәсенә, “Дәүләт һәм муниципаль милекне приватизацияләү турында”гы 21.12.2001 елгы № 178-ФЗ Федераль законга, 2008нче елның 30 маенда Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары белән расланган 115 санлы “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль милек белән идарә итү һәм тәртибе турында”гы нигезләмәсенә , “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 78 маддәсенә яраклы рәвештә Татарстан Республикасы Ютазы район Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Кушымтага яраклы рәвештә 2018нче елга Ютазы муниципаль районының муниципаль милекне приватизацияләүнең Прогноз планын( программасын) расларга.
2. Ютазы муниципаль районының Милек һәм җир бәйләнешләре палатасына 2018нче елга Ютазы муниципаль районының муниципаль милекне приватизацияләүнең Прогноз планын гамәлгә ашырырга тәкдим итәргә.
3. Әлеге карарны гамәлгә куюны контрольгә алуны җирлек Советлары белән үзара законнар, регламент буенча даими комиссиягә йөкләргә.
4. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында урнаштырыга.

Ютазы муниципаль районы башлыгы-
Ютазы муниципаль районы Советырәисе Р.М.Нуриев

Кушымта
Ютазы район Советы карары белән расланган
№ 8 “23” 03 2018 ел.

**Ютазы муниципаль районының 2018нче елга**
**муниципаль милекне приватизацияләүнең**
**Прогноз планы (программасы)**

**1 бүлек.2018нче елга муниципаль милекне приватизацияләүнең бурычлары**

2018нче елга муниципаль милекне приватизацияләүнең Прогноз планы (алга таба –приватизацияләүнең Прогноз планы) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 14 маддәсенә, “Дәүләт һәм муниципаль милекне приватизацияләү турында”гы 21.12.2001 елгы № 178-ФЗ Федераль законга, “ Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милке карамагындагы яки муниципаль милектә булып, урта һәм кече эшмкәрлек субъектлары тарафыннан арендаланган хәрәкәтсез милекне тартып алу һәм Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү турында”гы 22.07.2008 елгы №159-ФЗ, 2008нче елның 30 маенда Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары белән расланган 115 санлы “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль милек белән идарә итү һәм тәртибе турында”гы нигезләмәсенә яраклы рәвештә эшләнгән.

Муниципаль милек белән идарә итүнең базар экономик шартларында формалашучы өлеше буларак,2018нче елга муниципаль милекне приватизацияләүнең төп бурычлары “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе органнары бурычлары һәм муниципаль милекне приватизацияләү исәбенәмуниципаль милек структурасын оптимизацияләү, шулай ук “ Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милке карамагындагы яки муниципаль милектә булып, урта һәм кече эшмкәрлек субъектлары тарафыннан арендаланган хәрәкәтсез милекне тартып алу һәм Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү турында”гы 22.07.2008 елгы №159-ФЗ таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2018нче елда приватизацияләүнең төп бурычлары:

- муниципаль милекне приватизацияләүдән район бюджетынасалымбулмагankеремнәрне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- милекне тотуга район бюджетыннан чыгымнарны киметү.

Приватизация процессы нәтиҗәсендә “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге экономикасында структур үзгәрешләр түбәндәге сәбәпләр буенча көтелми:

- приватизациягә тәкъдим ителгән кеше яшәми торган биналарда милекчене алыштырудан муниципаль берәмлекнең экономик хәленә тәэсир итәрдәй җитештерү юк;

- “Бөгелмә аграр колледжы”ДБУ филиалын ябу муниципаль район гражданнарының һәм анда яшәүчеләрнең белем алу өлкәсендә хокукларын бозмый;
- ДБУ “ ЮРГВО” яңадан төзелгән бинага күчерелгән.

Милекне реализацияләүхакына район бюджетынаякынча 3млн. сумкеремалу күздә тотыла.

ПриватизацияләүнеңПрогноз планы белән яраклы рәвештә сатуга куелган объектларның якынча хакына бәяләү уздырганнан соң ачыклык кертеләчәк.

Приватизацияләүгә тәкъдим ителгән объектларның якынча прогноз бәясе базар конъюктурасыннан чыгып билгеләнгән.

2018нче елда приватизацияләү планлаштырылган милек исемлеге муниципаль гомуми милек структурасын алга таба оптимизацияләүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

**2 бүлек. 2018нче елда “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә приватизацияләү планлаштырылган муниципаль милек.**

| № | Объект | Адрес | Приватизацияләү юлы | Тормышка ашыру срогы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Уку корпусы бинасы (билгеләнеше: кеше яшәми торган,1 катлы,тышкы стеналарның материалы: төрле) мәйданы 430,7 кв.м., кадастр № 16:43:100118:313 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы, ш.т.Урыссубистәсе, Пионер урамы, 11 йорт | Ачык аукцион | 2 квартал | |
| 2 | Административ хуҗалык бинасы(билгеләнеше: кеше яшәми торган,1 катлы,тышкы стеналарның материалы: төрле) мәйданы 602,5кв.м., кадастр № 16:43:080101:118 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы,Ютазы авылы,Комсомол урамы, 59 йорт | Ачык аукцион | 2 квартал | |
| 3 | Столяр цех бинасы (билгеләнеше: кеше яшәми торган,1 катлы,тышкы стеналарның материалы: төрле) мәйданы 601,7кв.м., кадастр № 16:43:080101:117 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы,Ютазы авылы,Комсомол урамы, 59 йорт | Ачык аукцион | 2 квартал | |
| 4 | Материал саклау өчен склад (билгеләнеше: кеше яшәми торган,1 катлы,тышкы стеналарның | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы,Ютазы авылы,Комсомол урамы, 59 йорт | Ачык аукцион | 2 квартал | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | материалы: төрле) мәйданы 45,7 кв.м., кадастр № 16:43:080101:119 | | | | |
| 5 | Гараж һәм слесарьлык мастерскойлары (билгеләнеше: кеше яшәми торган,1 катлы,тышкы стеналарның материалы: кирпеч) мәйданы 172,5 кв.м., кадастр № 16:43:080105:77 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы,Ютазы авылы,Дмитров урамы, 6 йорт | Ачык аукцион | 3 квартал | |
| 6 | Кеше яшәми торган бина №1000(билгеләнеше: кеше яшәми торган,1 катлы,тышкы стеналарның материалы: кирпеч), мәйданы 285,6 кв.м., кадастр № 16:43:080105:77 | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы, ш.т.Урыссубистәсе, Ипи тыурыгы, 1 йорт | Ачык аукцион | 4 квартал | |